СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-26 от «28» декабря 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» № 8-9 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» № 8-9 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» № 8-9 карары белән расланган «Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген» яңа редакциядә түбәндәгечә бәян итәргә:

«1.Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.

2. Дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы адресына (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек биргән ысул белән) һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы

000145

затлар тарафыннан бозылуы турында фактларның алдагы календарь елның шул ук чоры һәм (яки) шуңа туры килә торган чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай, квартал)мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк үсүе .

3. Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртиптә, формаларда, срокларда һәм вакытта торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында булмавы.

4. Тикшерелә торган зат идарәсендә булган күпфатирлы йортта гомуми милекнең төзексезлеген бетерү эшләрен уздыру өчен ремонт бригадаларын атна саен биш мәртәбә чакырту, Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча.

5. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан арттыру турында белешмәләр ачыклану.»;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Район башлыгы урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов